**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советының карары**

Зур Сукаеш № 6 2018 елның "30" марты

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 27 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Сукаеш авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (2015 елның 14 февралендәге 1 номерлы, 2015 елның 3 сентябрендәге 22 номерлы, 2016 елның 4 мартындагы 6 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге № 299-ФЗ, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы федераль кануннарын үтәү өчен

Сукаеш авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 27 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Сукаеш авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертергә (2015 елның 14 февралендәге 1 номерлы, 2015 елның 3 сентябрендәге 22 номерлы, 2016 елның 4 мартындагы 6 номерлы карарлар редакциясендә) , 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1.4. Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Уставка, гамәлдәге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устав) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сукаеш авыл җирлеге Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис Закирова З.Җ.